ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР СУКСУЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

423736, Татар Суксуы авылы,
Гагарин ур.,1 б нче йорт.
Тел. 3-44-60
e–mail: tsuk-akt@yandex.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ТАТАРСКО-СУКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423736, с. Татарские Суксы,
ул. Гагарина, дом 1 б.
Тел. 3-44-60
e–mail: tsuk-akt@yandex.ru

# РЕШЕНИЕ

«28»март 2025 г. № 6

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Татар Суксуы авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» 24 март 2025 ел 5 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Татар Суксуы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 35 статьясы нигезендә, Совет Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге

карар итте:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Татар Суксуы авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» 24 март 2025 ел 5 нче номерлы карарына, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Татар Суксуы авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын һәм график сурәтен яңа редакциядә раслап үзгәреш кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматын рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга, торак пунктлар территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы, Мари-Суксу, Яңа Кормаш, Карт җирлегенең түбәндәге адреслары буенча халыкка җиткерергә:

Татар Суксы ав. Гагарин ур., 1А йорт (мәдәният йорты бинасы);
Мари-Суксу ав., Илекбай Миңлебай ур., 29 йорт (мәдәният йорты бинасы).
Яңа Кормаш ав., Үзәк ур., 41А йорт (мәдәният йорты бинасы).
Карт ав., Үзәк ур., 1б йорт (мәдәният йорты бинасы).

3. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татар Суксуы авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе Г.Г. Хамматуллина